ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.04.2020 Олы Кайбыч ав. № 198

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында

Язгы-җәйге чорда янгын куркынычы дәрәҗәсе арту һәм янгыннар белән бәйле вәзгыятьнең тотрыксызлыгын булдырмау өлешендә янгын куркынычы арту белән бәйле рәвештә, “Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» 2000 елның 1 апрелендәге 242 номерлы карары нигезендә, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 10 апреленнән 17 маена кадәр Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертергә.

2. Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда:

коры үлән һәм чүп-чар яндыру;

ачык утта (учак, мангалларда) ризык әзерләү, 1-3 класслы пиротехник эшләнмәләр куллануны тыярга.

3. Кайбыч муниципаль районы Җирлекләре Башлыкларына:

торак пунктлар территорияләрен корыган үләннән һәм чүп-чардан чистарту буенча чаралар күрергә;

баланста булган тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының эшкә яраклылыгын тикшерергә;

нигездә мобиль тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итүнең өстәмә чыганакларын булдыру буенча чаралар күрергә;

янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда янгын куркынычы булган эшләрне бары тик авария нәтиҗәләрен бетерү кирәк булган очракта гына башкарырга;

һәр авыл җирлегендә, янгыннарны иртә ачыклау һәм янгыннан саклануны үз вакытында хәбәр итү максатыннан, торак пунктларга

патрульлек итү буенча патруль-контроль төркемнәре булдырырга, аларның эшен оештырырга, төркемнәрнең эш графикларын эшләргә;

язгы-җәйге янгын куркынычы янаган чорда халык арасында янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалау буенча эшне планлаштырырга һәм үткәрергә;

янгын куркынычы сезоны башланганчы торак пунктларны һәм икътисад объектларын табигать янгыннарыннан саклау өчен минераллаштырылган полосалар булдыру, территорияләрне чүп-чардан һәм коры-сарыдан чистарту эшләрен төгәлләргә;

урман янгыннары хәле катлауланган чорда ирекле һәм муниципаль Янгын сагы әгъзаларының тәүлек буе кизү тору планнарын төзергә, шулай ук су сиптерү һәм янгын сүндерү өчен башка җайлаштырылган техниканы җәлеп итү планнарын төзергә;

Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ ДИ ФЯКХ 115 янгын-коткару частенең 8 янгын-коткару отряды белән берлектә табигый янгыннар белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү, торак пунктларны, икътисад һәм социаль инфраструктура объектларын урман янгыннарыннан саклау, шулай ук муниципальара урман янгыннарын сүндерү өчен билгеләнгән көчләрне һәм чараларны маневрлау буенча комплекслы өйрәнүләр үткәрергә;

табигый янгыннар килеп чыккан очракта халыкка хәбәр итү һәм эвакуацияләү мәсьәләләрен эшләргә;

кешеләрне вакытлыча урнаштыру пунктларының янгын куркынычы янаган чорда эшләргә әзерлеген тикшерергә;

эвакуацияләнгән халыкның беренче чиратта яшәешен тәэмин итү планнарын эшләргә;

янгын турында хәбәр итү чараларының тотрыклы эшен тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Апас һәм Кайбыч муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр районара бүлегенә тәкъдим итәргә:

привентив янгын-профилактик чаралар комплексын планлаштырырга һәм үткәрергә;

массакүләм мәгълүмат чараларында торак пунктларда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге проблемалы мәсьәләләрне яктыртырга, шулай ук янгын куркыныы чорында халыкка янгын куркынычсызлыгы чаралары турында хәбәр итәргә;

Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләренә урман янгыннары куркынычы янаган торак пунктларның паспортларын эшләүдә (актуальләштерү) консультатив һәм методик ярдәм күрсәтергә;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы «Янгынга каршы режим турында» карары белән расланган Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләрен исәпкә алып, коры үлән үсемлекләрен яндыру тәртибен, шулай ук Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм запас җирләрендә ачык ут куллану һәм учаклар ягу тәртибен

раслау турында» 2016 елның 26 гыйнварындагы 26 номерлы боерыгын аңлату буенча эш оештырырга;

планлы (рейд) тикшерүләр үткәрергә, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча территорияләрне, бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрен тикшерергә.

5. Россия ГТХМ ДИ ФЯКХ 115 янгын-коткару частенең 8 янгын-коткару отрядына:

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системаның муниципаль звенолары көчләренең һәм чараларының табигать янгыннарын сүндерүгә әзерлеген тикшерергә;

торак пунктларны, икътисад объектларын табигый янгыннардан саклауны контрольгә алырга, шулай ук табигый янгын чыганакларын үз вакытында ачыклау һәм аларны ачыкланган көнне юк итү эшен оештырырга;

космик мониторинг чаралары (термик нокталар) тарафыннан табылган янгыннар турында сигналларга вакытында җавап бирүне тәэмин итәргә.

6. «Кайбыч урманчылыгы» ДКУ Кайбыч участок урманчылыгына тәкъдим итәргә:

Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары белән берлектә урман янгыннарын профилактикалауга һәм аларга каршы көрәшкә юнәлдерелгән оештыру-техник чаралар үткәрүне тәэмин итәргә;

урман массивларында һәм алар янында урнашкан табигый һәм ясалма сулыклардан янгын сүндерү техникасы белән су алу өчен мәйданчыклар төзүне дәвам итәргә;

урман янгыннарын башлангыч стадиядә ачыклауга, локальләштерүгә һәм бетерүгә юнәлдерелгән оператив чаралар күрүне тәэмин итәргә;

урман янгыннарын сүндерү өчен янгынга каршы техниканы, транспорт чараларын, шулай ук урман янгыннарын сүндерү планнары нигезендә юридик затларны һәм гражданнарны җәлеп итәргә;

Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетларына торак пунктларның урман массивларына тоташкан чикләре буйларындагы минераллаштырылган полосаларны төзекләндерүдә ярдәм күрсәтергә;

янгын куркынычы сезоны башланганчы:

урман фондында эшләр башкаручы оешмаларның урман янгыннарын сүндерүгә көчләренең һәм чараларының әзерлеген тикшерергә;

билгеләнгән нормативлар нигезендә урман янгыннары формированиеләрен шәхси состав белән комплектлап бетерергә, шәхси составны укытуны оештырырга;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына караган дәүләт бюджет учреждениеләре карамагындагы махсус урман янгыннарын сүндерү техникасын һәм җиһазларын техник яктан төзек хәлгә китерергә;

урманнарны авиапатрульләү буенча чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ ДИ ФЯКХ 115 янгын-коткару частенең 8 янгын-коткару отрядына Апас һәм Кайбыч муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик

эшләр районара бүлеге белән берлектә:

2020 елның 10 апреленнән 17 маена кадәр янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү буенча гражданнарның күпләп ял итү урыннарына һәм урманнарга патрульлек итәргә;

урман янгыннары белән бәйле гадәттән тыш хәлләр килеп куркынычы булганда һәм барлыкка килгәндә халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары аша гамәлләр алгоритмы буенча мәгълүмат җиткерүне оештырырга;

халык арасында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша торак пунктларда һәм урманнарда язгы-җәйге чорда янгыннарны профилактикалау мәсьәләләре буенча максатчан эш оештырырга;

гражданнар белән җыеннарда янгынны сүндерү һәм гадәттән тыш хәл зонасыннан эвакуацияләүгә өйрәтү буенча дәресләр үткәрергә;

муниципаль, ведомство, шәхси һәм ирекле янгын формированиеләренең, урман янгыннары формированиеләренең, табигый янгыннарны торак пунктларга һәм икътисад объектларына күчерү куркынычы янаганда практик гамәлләрне эшләү буенча әзерлеген тикшерүне оештырырга.

7. Районның авыл хуҗалыгы предприятиеләренә:

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм запастагы җирләрдә ачык ут куллану һәм учаклар ягу тәртибен раслау турында» 2016 елның 26 гыйнварындагы 26 номерлы боерыгы таләпләрен тайпылышсыз үтәү буенча чаралар күрергә;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм алар янәшәсендәге урман массивларында язгы кыр һәм урып-җыю эшләре вакытында авыл хуҗалыгы оешмалары һәм фермер хуҗалыклары тарафыннан урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашырырга;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә коры үлән, камыл калдыклары һәм агач-куак үсемлекләре ягуны булдырмаска;

торак пунктларга, урман һәм торфлы массивларга, дала полосасына, автомобиль юлларына кырларның кибү урыннарын сөрүне башкарырга;

авыл хуҗалыгы оешмалары территориясен чүп-чардан һәм коры-сарыдан чистартырга, кирәк булган очракта, балансга булган янгын сүндерү максатларында тәүлек буе кизү торырга, шулай ук төзек булмаган янгын техникасын ремонтларга тәкъдим итәргә.

8. Россия Эчке эшләр министрлыгының Кайбыч районы буенча бүлегенә урман – парк зоналарына һәм гражданнарның күпләп ял итү урыннарына патрульлек итү чорында «Кайбыч урманчылыгы» ДКУнең Кайбыч участок урманчылыгына, Россия ГТХМ ДИ ФЯКХ 115 янгын-коткару частеның 8 янгын-коткару отрядына һәм Апас һәм Кайбыч муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр районара бүлегенә законнарда каралган тәртиптә ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

9. «Тататвтодор» АҖ ДРСУ Кайбыч участогына тәкъдим итәргә:

янгын куркынычы сезоны башланганчы, төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаны һәм төзекләндерү элементларын янгынга каршы яклауның кирәкле чараларын күрергә;

төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларын, юл кырыйларын һәм бүленгән полосаларын чүп-чардан, кирәкмәгән үлән һәм агач-куак үсемлекләреннән системалы рәвештә чистартуны тәэмин итәргә.

10. «Татмедиа» АҖ «Кайбыч таңнары» Кайбыч филиалына Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Апас һәм Кайбыч муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр районара бүлеге белән берлектә:

язгы-җәйге чорда торак пунктларда һәм урманнарда янгын куркынычсызлыгын пропагандалаучы видео-һәм аудиороликлар эшләргә һәм аларны район интернет сайтында трансляцияләүне оештырырга;

газетада халыкка үзеңне тотуның куркынычсыз кагыйдзләре белән таныштыра торган «Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы кисәтә» профилактик рубрикасы оештырырга тәкъдим итәргә.

11. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

12.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Н. Макаров